

## 19 нчы февраль 14:00

# Шагыйрь хисләре...

Муса Җәлил тууына **119** ел булуга багышланган әдәби кичә

**Шәрәфле кунаклар:**
**Муса Җәлил музее директоры Айгөл Сафиуллина;**
**Муса Җәлил премиясе лауреаты,**
**шагыйрь Рифат Сәлах**

*79 нчы экология-технология лицее*




***19 февраль көнне халкыбызның горурлыгы булган каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 119 ел булу уңаеннан, үсеп килүче яшь буында бөек шәхесләргә, татар әдәбиятына карата мәхәббәт тәрбияләү максатыннан лицеебызда «Шагыйрь хисләре...» дип исемләнгән шигърият кичәсе үтте. Чарага шәрәфле кунаклар буларак Муса Җәлилнең музей-фатиры директоры Айгөл Сафиуллина һәм Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты, шагыйрь Рифат Сәлах чакырулы иде. Алар лицей укучыларын Муса Җәлилнең "Моабит дәфтәрләре", җәлилчеләр кылган батырлыклар белән таныштырдылар. Шигърият кичәсендә кунаклар, лицей укучылары, укытучылар каһарман шагыйрьнең "Дару", "Вәхшәт", "Кызыл ромашка", "Урман", "Яшь ана", "Бер үгет", "Шагыйрь", "Кыз җыры", "Хәдичә", "Томаулы гыйшык" кебек шигырьләрен, истәлекләр укыдылар. Кичәдә М.Җәлилнең рус, инглиз теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре дә яңгырады.***

***Муса Җәлил кебек бөек шәхесләргә мәңгелек дан!***


Моабит дәфтәре






Батыр үлә, үлмәс ат алып,
Батырлыклар белән макталып,
Исмең калсын, үзең үлсәң дә,
Тарихларда укып ятларлык.
Муса Җәлил.




МУСА ҖӘЛИЛ
«Онытма! Хәтерлә!


Тау башына салынгандыр безнең авыл.
Бер чишмә бар — якын безнең авылга ул.
Авылыбызның суы тәмен, ямен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән...
Г. Тукай